**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2020 елның «21» апреленнән № 94

**«Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 25.09.2013 ел, № 406 карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль ярдәмнең аерым чараларын бирү срогын озайту турында» 2020 елның 1 апрелендәге 241 номерлы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елныә 25 сентябрендәге 406 нчы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенә (Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 17.01.2014 ел, № 15, 14.02.2017 ел, № 84, 19.01.2018 ел, № 25, 16.09.2009 ел, № 230 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче Бүлектәге "Компенсацияне билгеләү һәм түләү Тәртибе»нә түбәндәге эчтәлекле 2.9 пунктчасын өстәргә:

«Түләү чоры 2020 елның 30 сентябренә кадәр чыга торган социаль ярдәм чараларын бирү срогын, аларны алу өчен кабат гариза бирмичә, 2020 елның 1 октябренә кадәр озайтырга».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының «Интернет" мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**Җитәкчесе** **Р.Р.Фәсахов**